ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«09» марта 2022 ел № 47

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 26 апрелендәге 194 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында»2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында»2011 елның 7 декабрендәге 1189 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары нигезендә, социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүне тәртипкә салу максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 26 апрелендәге 194 номерлы карарында кушымта итеп бирелә торган үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru.
3. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Шәриповка йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетынын
09.03.2022 № 47
карары белән расланган

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетынын «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 26 апрелендәге 194 номерлы карарына
ҮЗГӘРЕШЛӘР

1) 1 пунктта:
икенче абзацта «компенсация түләүләре,» сүзләрен төшереп калдырырга.

2) 5 пунктта:

1 пунктчада «50» санын «8» санына алмаштырырга;

3 пунктчада «айлык тариф ставкасынын 25 проценты күләмендә премияне исәпкә алып, ике айлык тариф ставкасы» сүзләрен «айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктчада:

икенче абзацта «25» санын «5» санына алмаштырырга;

өченче абзацта «10» санын «2» санына алмаштырырга;

6 пунктчада:

өченче абзацта «35» санын «7» санына алмаштырырга;

бишенче абзацта «50» саннарын «10» саннарына алмаштырырга.

3) 8 пунктта:

беренче абзацта "(компенсация түләүләрен исәпкә алып)" сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктчада «тугыз айлык тариф ставкасы» сүзләрен «бер бөтен уннан сигез айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктчада «өч айлык тариф ставкалары» сүзләрен «бер айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктчада «айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендә премияне исәпкә алып, ике айлык тариф ставкасы» сүзләрен «айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга.